# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы
Чукмарлы авыл җирлегенең Чукмарлы авылы торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

**30 март 2024 ел** **№1**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Чукмарлы авыл җирлеге башлыгынын 20.03.2024 ел 1 нче номерлы "«Чукмарлы авыл җирлеге Чукмарлы торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 15 ноябрендәге 1 номерлы, «Сарман муниципаль районы Чукмарлы авыл җирлегенең Чукмарлы торак пунктында 2024 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында» 2023 елның 15 ноябрендәге 2 номерлы гражданнар жыены карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча Сарман муниципаль районы Чукмарлы авыл җирлегенең Чукмарлы торак пунктында гражданнар җыены билгеләү турында" карары
нигезендә 2024 елның 30 мартында 10.00 сәгатьтә узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән протокол төзелде. Гражданнар җыенына түбәндәге сораулар тәкъдим ителде.

«Чукмарлы авыл җирлеге Чукмарлы торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 15 ноябрендәге 1 номерлы, «Сарман муниципаль районы Чукмарлы авыл җирлегенең Чукмарлы торак пунктында 2024 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында» 2023 елның 15 ноябрендәге 2 номерлы гражданнар жыены карарларына үзгәрешләр кертергә ризамы, чараларны түбәндәге редакциядә бәян итеп:

«1. Традицион күмү урыннарын ремонтлау, киртәләр төзү, төзекләндерү (Чукмарлы торак пунктындагы зират территориясен киңәйтү, төзелеш материаллары сатып алу һәм койма урнаштыру буенча эш өчен түләү);
2. Урамнарны яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка мәйданчыкларны ремонтлау (Чукмарлы авылында лампаларны, энергияне сак тотучы тотучы яктырткычларны сатып алу һәм урнаштыру);
3. Су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу системаларын, су күтәрү манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортлауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау; (Комсомол, Совет урамы су башняларын ремонтлау)

4. Торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Чукмарлы авылында Комсомол урамы, Совет урамы, Яшьләр урамнарындагы юлларны кардан чистарту);

5. Чукмарлы торак пунктында янгын куркынычсызлыгы буенча чараларны тәэмин итү (2 дана янгын ранеецлар сатып алу) .

6.Торак пункт территориясен төзекләндерү (Чукмарлы торак пунктында җәйге вакытта территорияне чабу; бензокосилка һәм Беларусь МТЗ 82 өчен ягулык-майлау материаллары сатып алу, Беларусь МТЗ 82 тракторы өчен запас частьләр сатып алу;)

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Җыенда катнашучылар исемлегенә сайлау хокукына ия булган 232 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны - 161 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

гражданнар җыенында «РИЗА» позициясе өчен 161 катнашучы тавыш бирде; «КАРШЫ» позициясе өчен 0 катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карар итте:

1. Сарман муниципаль районының Чукмарлы авыл жирлегенең Чукмарлы авылы торак пунктында гражданнар җыенын узган дип танырга, гражданнар җыены нәтиҗәләрен гамәлдә дип танырга.

2. Түбәндәге сораулар буенча :

«Чукмарлы авыл җирлеге Чукмарлы торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 15 ноябрендәге 1 номерлы, «Сарман муниципаль районы Чукмарлы авыл җирлегенең Чукмарлы торак пунктында 2024 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында» 2023 елның 15 ноябрендәге 2 номерлы гражданнар җыены карарларына үзгәрешләр кертергә ризамы, чараларны түбәндәге редакциядә бәян итеп:

«1. Традицион күмү урыннарын ремонтлау, киртәләр төзү, төзекләндерү (Чукмарлы торак пунктындагы зират территориясен киңәйтү, төзелеш материаллары сатып алу һәм койма урнаштыру буенча эш өчен түләү);

2. Урамнарны яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка мәйданчыкларны ремонтлау (Чукмарлы авылында лампаларны, энергияне сак тотучы тотучы яктырткычларны сатып алу һәм урнаштыру);

3. Су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу системаларын, су күтәрү манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортлауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау; (Комсомол, Совет урамы су башняларын ремонтлау)

4. Торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Чукмарлы авылында Комсомол урамы, Совет урамы, Яшьләр урамнарындагы юлларны кардан чистарту);

5. Чукмарлы торак пунктында янгын куркынычсызлыгы буенча чараларны тәэмин итү (2 дана янгын ранеецлар сатып алу) .

6.Торак пункт территориясен төзекләндерү (Чукмарлы торак пунктында җәйге вакытта территорияне чабу; бензокосилка һәм Беларусь МТЗ 82 өчен ягулык-майлау материаллары сатып алу, Беларусь МТЗ 82 тракторы өчен запас частьләр сатып алу;) карарны кабул ителгән дип санарга.

3. Гражданнар җыены нәтиҗәләрен Чукмарлы авыл җирлегенең Чукмарлы мәгълүмати стендларына урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Сарман муниципаль районының рәсми сайтында (http:/ https://sarmanovo.tatarstan.ru/), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 7 көн эчендә бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Чукмарлы авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Сарман муниципаль районы
Чукмарлы авыл җирлеге башлыгы,
Халык җыенында рәислек итүче                И.Х.Хадиуллин